| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУШМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОШМАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.03.2019 г. Кошман авылы № 3

**«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Җирләү һәм җирләү эше турында»гы 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, «2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында»гы Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә беренче һәм икенче номерлы кушымталар нигезендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 5946,47 сум күләмендә билгеләргә.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://kushman-kaybici.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Кошман авыл җирлеге**
**Башкарма комитет җитәкчесе** **Л.Р.Сафина**

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ Кушманского сельского поселения ИНН 1621003133

Кошман авыл җирлеге
Башкарма комитетның
2019 ел, 12 март, 3 нче номерлы
карарына1 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәт күрсәтүнең бәясе**

| **Хезмәткүрсәтүисемлеге** | **Хезмәт күрсәтү бәясе сумнарда** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Күмү өчен табут һәм башка кирәк – яракларны китереп бирү | 2551,18 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәден) алып бару | 682,98 |
| 4.Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2712,31 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |

Кошман авыл җирлеге
Башкарма комитетның
2019 ел, 12 март, 3 нче номерлы
карарына 2 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының
Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәт күрсәтүнең бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү исемлеге** | **Хезмәт күрсәтү бәясе сумнарда** |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетнең гәүдәсен ахирәт киеменә киендерү | 320,72 |
| 3. Күмү өчен табут һәм башка кирәк – яракларны китереп бирү | 2230,46 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәден) алып бару | 682,98 |
| 5.Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2712,31 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |